| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 март 2014 ел № 7-4/т

Казан
шәһәре

***Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы Биектау тимер юлы поселогы һәм Биектау авылында җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы Биектау тимер юлы поселогы һәм Биектау авылында җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләргә.
2. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 06 март 2014 ел № 7-4/т карарына кушымта

Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районы Биектау тимер юлы поселогы һәм Биектау авылында җәмәгать автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары

| № п/п | Уңайлык исеме | Бер тапкыр баруның максималь чик тарифы (ӨБС алынмый), сум |
|---|---|---|
| 1 | Пассажирларны автобуста алып бару | 15 |
| 2 | Автобуста 1 багаж урынын алып бару | 15 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге